**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.07. 2021 ел № 59

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югарысәрдә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы уставы нигезендә, 2021 елның 24 июнендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Җир белән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2021 елның 28 июнендәге 131-ФЗ номерлы бәяләмәне исәпкә алып, 2021 елның 24 июнендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югарысәрдә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2021 елның 28 июнендәге бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югарысәрдә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югарысәрдә авыл җирлегенә территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югарысәрдә авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен урнаштыруны тәэмин итәргә(https://fgistp.economy.gov.ru/).

3. Әтнә муниципаль районының Югарысәрдә авыл җирлеге советына, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югарысәрдә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында элегрәк кабул ителгән карарны үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә

муниципаль районы Советының гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен, җәмәгать тәртибен һәм җирле үзидарәне саклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы
Әтнә район Советы Рәисе Г.Г.Хәкимов